ГЛАВА БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Байряки-Тамак, ул.Новая, д.37, , 423964

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ-ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Бәйрәкә-Тамак авылы, Яңа урамы, 37 йорт, 423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail: Btam.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

N 1 14.03.2024 ел

2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Бәйрәкәтамак торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 маддәләренә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2023 елның 10 ноябрендәге 34 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26, 92 маддәләре, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 10 сентябрендәге 11 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында»гы нигезләмәнең 4 пунктының 4.4 пунктчасына ярашлы,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 25 мартында 09 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Бәйрәкәтамак торак пункты, Яңа урам, 36 йорт адресы буенча урнашкан күпфункцияле үзәк бинасы янында, 2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Бәйрәкәтамак торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләләрне расларга:

2.1. «2023 елның 17 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Бәйрәкәтамак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 1 санлы карарын гамәлдән чыгарырга сез ризамы?».

2.2. «Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Бәйрәкәтамак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, 1 төркем инвалидлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым (бер тапкыр түләүләр) кертүгә ризамы һәм әлеге акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез ризамы:

- Бәйрәкәтамак торак пунктында традицион күмү урыннарын төзекләндерү ремонтлау, коймалау (зират территориясен койма белән уратып алу, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Бәйрәкәтамак торак пунктында торак пункт территориясен төзекләндерү (халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау (балалар мәйданчыгы өчен МАФ сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Байрәкәтамак торак пунктында торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирлек эчендәге юлларны карап тоту, кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын әзерләүне һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru электрон адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы З.М.Әһлиева